ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 п.г.т.Алексеевское № 48

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче гражданның 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәтенең бәясен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бердәм торак комиссиясен төзү турында» 2018 елның 21 декабрендәге 470 номерлы карары белән,

**карар бирәм:**

1. 2024 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик кыйммәтләрен билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясе чиге:

1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен- 612 252 сум.;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен -1 224 504 сум.;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен -1 836 756 сум.;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен- 2 449 008 сум.;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен- 3 061 260 сум.;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен- 3 673 512 сум.;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен- 4 285 762 сум.;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен -19 875 сум.;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен-19 875 сум.;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен-19 875 сум.;

2. Бердәм торак Комиссиясе әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларына таянып, гаиләнең һәр әгъзасының яки ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә,

аларны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ дип тану максатында эш итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.02.2024 № 48
карарына кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү хисабы**

1. СЖ = НП х РС х РПС, монда

СЖ - базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече яки милек бәясе чиге;

НП - бер гаилә әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РПС - торак мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе – 34 014 сум. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерцияле булмаган оешмасының 23.01.2024 елның 10 номерлы хатының уртача бәясе кулланылды.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 34 014 х 18 х 1 = 612252 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 2 = 1224504 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 3 = 1836756 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 4 = 2449008 сум
д) биш кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 5 = 3061260 сум
е) алты кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 6 = 3673512 сум
ж) җиде кешелек гаиләгә:
СЖ = 34 014 х 18 х 7 = 4285762 сум

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте:

$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС/(1-(1 + ПС)^{-КП})/(0,3 \times РС)$, монда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны сатып алуның базар бәясенең исәп хисап күрсәткече;

ПС - айлык кредит буенча процент ставкасы (16% еллык яки 16/100/12 аена, башлангыч взнос шарты белән 30%);

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (кредит бирү вакыты 20 ел яки 240 ай) «Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы»АҖ мәгълүматлары буенча;

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык кереме белән нисбәте,

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 х 612252 х (16/100/12)/ (1- (1 + (16/100/12))-240) /(0,3 х 1) = 19875 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 х 1224504 х (16/100/12)/ (1-(1 + (16/100/12))-240) /(0,3 х 2)= 19875 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә;

ПД = 0,7 х 1836756 х (16/100/12)/ (1-(1 + (16/100/12))-240) /(0,3 х 3)= 19875 сум